**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О наделении органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан полномочиями Российской Федерации по подготовке и проведению Всероссийской переписи населения 2020 года

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
26 ноября 2020 года

## Статья 1. Предмет регулирования настоящего Закона

Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 25 января 2002 года № 8-ФЗ «О Всероссийской переписи населения», Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», Законом Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», иными нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан наделяет органы местного самоуправления муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления) полномочиями Российской Федерации по подготовке и проведению Всероссийской переписи населения 2020 года, переданными для осуществления органам государственной власти Республики Татарстан (далее – полномочия).

## Статья 2. Полномочия, которыми наделяются органы местного самоуправления

Органы местного самоуправления наделяются следующими полномочиями:

1) обеспечение помещениями, охраняемыми, оборудованными мебелью, средствами связи и пригодными для обучения и работы лиц, привлекаемых к сбору сведений о населении;

2) обеспечение охраняемыми помещениями для хранения переписных листов и иных документов Всероссийской переписи населения 2020 года;

3) предоставление необходимых транспортных средств, средств связи.

**Статья 3. Наименования муниципальных образований Республики Татарстан, органы местного самоуправления которых наделяются полномочиями**

Полномочиями наделяются органы местного самоуправления следующих муниципальных образований Республики Татарстан (далее – муниципальные образования):

город Казань, «город Набережные Челны», Агрызский муниципальный район, Азнакаевский муниципальный район, Аксубаевский муниципальный район, Актанышский муниципальный район, Алексеевский муниципальный район, Алькеевский муниципальный район, Альметьевский муниципальный район, Апастовский муниципальный район, Арский муниципальный район, Атнинский муниципальный район, Бавлинский муниципальный район, Балтасинский муниципальный район, Бугульминский муниципальный район, Буинский муниципальный район, Верхнеуслонский муниципальный район, Высокогорский муниципальный район, Дрожжановский муниципальный район, Елабужский муниципальный район, Заинский муниципальный район, Зеленодольский муниципальный район, Кайбицкий муниципальный район, Камско-Устьинский муниципальный район, Кукморский муниципальный район, Лаишевский муниципальный район, Лениногорский муниципальный район, Мамадышский муниципальный район, Менделеевский муниципальный район, Мензелинский муниципальный район, Муслюмовский муниципальный район, Нижнекамский муниципальный район, Новошешминский муниципальный район, Нурлатский муниципальный район, Пестречинский муниципальный район, Рыбно-Слободский муниципальный район, Сабинский муниципальный район, Сармановский муниципальный район, Спасский муниципальный район, Тетюшский муниципальный район, Тукаевский муниципальный район, Тюлячинский муниципальный район, Черемшанский муниципальный район, Чистопольский муниципальный район, Ютазинский муниципальный район.

**Статья 4. Срок, на который органы местного самоуправления наделяются полномочиями**

Органы местного самоуправления наделяются полномочиями на 2021 год.

**Статья 5. Финансовое обеспечение полномочий**

1. Финансовое обеспечение расходных обязательств муниципальных образований, возникающих при осуществлении органами местного самоуправления полномочий, осуществляется за счет средств федерального бюджета, предоставляемых бюджету Республики Татарстан в форме субвенций.

Субвенции на осуществление органами местного самоуправления полномочий предоставляются местным бюджетам из бюджета Республики Татарстан.

2. Общий объем субвенций для осуществления органами местного самоуправления полномочий и его распределение между муниципальными

образованиями определяются в соответствии с Методикой определения объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления полномочий Российской Федерации по подготовке и проведению Всероссийской переписи населения 2020 года, согласно приложению к настоящему Закону.

3. Объем субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных образований для осуществления органами местного самоуправления полномочий, устанавливается законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год и плановый период.

Статья 6. **Материальные средства, передаваемые в безвозмездное пользование органам местного самоуправления для осуществления полномочий**

1. Материальные средства, находящиеся в собственности Республики Татарстан, в случае необходимости обеспечения осуществления полномочий передаются в безвозмездное пользование органам местного самоуправления в соответствии с перечнем передаваемых материальных средств.

2. Разработка перечня передаваемых материальных средств, его утверждение и принятие решения о передаче материальных средств осуществляются органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области имущественных отношений, на основании подготовленного с учетом предложений органов местного самоуправления обращения уполномоченного органа исполнительной власти Республики Татарстан, ответственного за подготовку и проведение Всероссийской переписи населения 2020 года в Республике Татарстан, определяемого Кабинетом Министров Республики Татарстан (далее – специально уполномоченный орган).

Статья 7. **Права и обязанности органов местного самоуправления при осуществлении полномочий**

1. Органы местного самоуправления при осуществлении полномочий имеют право на:

1) финансовое обеспечение полномочий за счет предоставляемых местным бюджетам субвенций из бюджета Республики Татарстан;

2) обеспечение полномочий необходимыми материальными средствами;

3) дополнительное использование собственных материальных ресурсов и финансовых средств для осуществления полномочий в случаях и порядке, предусмотренных уставом муниципального образования;

4) получение в органах государственной власти Республики Татарстан информационной, консультативной, организационной и методической помощи по вопросам осуществления полномочий.

2. Органы местного самоуправления при осуществлении полномочий обязаны:

1) определять органы местного самоуправления и их должностных лиц,

ответственных за осуществление полномочий;

2) соблюдать законодательство Российской Федерации и Республики Татарстан, а также акты органов исполнительной власти Республики Татарстан, принятые в пределах их компетенции по вопросам осуществления полномочий;

3) обеспечивать учет и рациональное использование материальных средств, находящихся в собственности Республики Татарстан и передаваемых в безвозмездное пользование органам местного самоуправления для осуществления полномочий, эффективное и целевое использование финансовых средств, предоставленных из бюджета Республики Татарстан на осуществление полномочий;

4) представлять уполномоченным органам исполнительной власти Республики Татарстан необходимую информацию и документы, связанные с осуществлением полномочий, использованием выделенных на эти цели материальных и финансовых средств;

5) представлять уполномоченным органам исполнительной власти Республики Татарстан отчеты об осуществлении полномочий и расходовании финансовых средств;

6) оказывать содействие уполномоченным органам исполнительной власти Республики Татарстан в осуществлении контроля за реализацией полномочий.

Статья 8. **Права и обязанности органов государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления полномочий**

1. В соответствии с Федеральным законом от 25 января 2002 года № 8-ФЗ «О Всероссийской переписи населения», Федеральным законом от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» Президент Республики Татарстан:

обеспечивает проведение контроля за эффективностью и качеством осуществления органами местного самоуправления полномочий;

выступает с законодательной инициативой о прекращении осуществления органами местного самоуправления переданных в соответствии со статьей 1 настоящего Закона полномочий в случае их неисполнения или ненадлежащего исполнения.

2. Органы государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления полномочий вправе:

1) принимать обязательные для исполнения нормативные правовые акты и осуществлять контроль за их исполнением;

2) запрашивать информацию, материалы и документы, связанные с осуществлением полномочий;

3) давать письменные предписания по устранению нарушений, допущенных органами местного самоуправления или их должностными лицами в ходе осуществления полномочий, в том числе по устранению нарушений требований настоящего Закона;

4) осуществлять координацию деятельности органов местного самоуправления по вопросам осуществления полномочий.

3. Органы государственной власти Республики Татарстан при осуществлении органами местного самоуправления полномочий обязаны:

1) передавать органам местного самоуправления материальные и финансовые средства, необходимые для осуществления полномочий;

2) рассматривать предложения органов местного самоуправления по вопросам осуществления полномочий;

3) осуществлять контроль за исполнением органами местного самоуправления полномочий, а также за использованием предоставленных на эти цели материальных и финансовых средств;

4) предоставлять органам местного самоуправления по их запросам информацию по вопросам осуществления полномочий;

5) оказывать информационную, консультативную, организационную и методическую помощь по вопросам осуществления полномочий.

Статья 9. **Порядок отчетности органов местного самоуправления об осуществлении полномочий**

Отчеты об осуществлении полномочий представляются органами местного самоуправления в порядке, сроки и по формам, установленным нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан.

Статья 10. **Контроль за осуществлением органами местного самоуправления полномочий**

Контроль за осуществлением органами местного самоуправления полномочий осуществляется:

1) специально уполномоченным органом путем:

а) запросов необходимых документов, отчетов и информации об исполнении полномочий;

б) проведения проверок в порядке, предусмотренном статьей 77 Федерального закона от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации»;

2) в случае передачи в безвозмездное пользование органам местного самоуправления материальных средств, находящихся в собственности Республики Татарстан, для осуществления полномочий, предусмотренных настоящим Законом, органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области имущественных отношений, в части сохранности и надлежащего использования государственного имущества, переданного органам местного самоуправления для осуществления полномочий, путем:

а) запросов необходимых документов, отчетов и информации об исполнении полномочий;

б) проведения проверок в порядке, предусмотренном статьей 77 Федерального закона от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации»;

в) принятия необходимых мер по устранению нарушений и их предупреждению;

3) органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области финансовой политики, в части целевого использования финансовых средств, переданных для осуществления полномочий, в соответствии с бюджетным законодательством Российской Федерации и иными нормативными правовыми актами, регулирующими бюджетные правоотношения.

### Статья 11. **Условия и порядок прекращения осуществления органами местного самоуправления полномочий**

1. Прекращение осуществления органами местного самоуправления полномочий производится законом Республики Татарстан в случае:

1) неисполнения или ненадлежащего исполнения органами местного самоуправления требований законодательства по осуществлению полномочий;

2) неисполнения органами местного самоуправления и их должностными лицами предписаний об устранении нарушений настоящего Закона;

3) изменения федерального законодательства или законодательства Республики Татарстан, в результате которого осуществление органами местного самоуправления полномочий становится невозможным.

2. Прекращение осуществления органами местного самоуправления полномочий влечет за собой возврат неиспользованных финансовых и материальных средств, переданных для осуществления полномочий.

3. В случае неисполнения или ненадлежащего исполнения органами местного самоуправления требований законодательства по осуществлению полномочий специально уполномоченный орган в течение 10 дней со дня выявления указанных нарушений направляет в органы местного самоуправления предписание об их устранении.

4. Предписание об устранении выявленных нарушений подлежит обязательному рассмотрению не позднее чем в 10-дневный срок со дня его поступления в орган местного самоуправления. О результатах рассмотрения предписания незамедлительно сообщается в письменной форме в специально уполномоченный орган.

5. В случаях, предусмотренных частью 1 настоящей статьи, специально уполномоченный орган вносит на рассмотрение Кабинета Министров Республики Татарстан предложение о прекращении осуществления органами местного самоуправления полномочий и соответствующий проект закона Республики Татарстан.

### Статья 12. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2021 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
11 декабря 2020 года
№ 86-ЗРТ

Приложение
к Закону Республики Татарстан
«О наделении органов местного
самоуправления муниципальных
районов и городских округов
Республики Татарстан полномочиями
Российской Федерации по подготовке и
проведению Всероссийской переписи
населения 2020 года»

**Методика**
**определения объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления полномочий Российской Федерации по подготовке и проведению Всероссийской переписи населения 2020 года**

1. Настоящая Методика разработана в целях определения объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных образований из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления полномочий.

2. Общий объем субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных образований для осуществления полномочий ($V_{РТ}$), определяется по формуле:

$$V_{РТ} = \sum_{i=1}^{n} V_{общ_i},$$

где:

n – количество муниципальных образований, наделенных полномочиями;

i – муниципальное образование;

$Vобщ_i$ – объем субвенции, предоставляемой бюджету i-го муниципального образования (тыс. рублей).

3. Объем субвенции, предоставляемой бюджету i-го муниципального образования, определяется по формуле:

$$Vобщ_i = Vрпу_i + Vохр_i + Vтрс_i ,$$

где:

$Vрпу_i$ – размер затрат на обеспечение помещениями, охраняемыми, оборудованными мебелью, средствами связи и пригодными для обучения и работы лиц, привлекаемых к сбору сведений о населении, в i-м муниципальном образовании;

$Vохр_i$ – размер затрат на обеспечение охраняемыми помещениями для хранения переписных листов и иных документов Всероссийской переписи населения 2020 года в i-м муниципальном образовании;

$Vтрс_i$ – размер затрат на предоставление необходимых транспортных средств, средств связи в i-м муниципальном образовании.

4. Размер затрат на обеспечение помещениями, охраняемыми, оборудованными мебелью, средствами связи и пригодными для обучения и работы лиц, привлекаемых к сбору сведений о населении, в i-м муниципальном образовании определяется по формуле:

$$Vрпу_i = Сб_i \times Пn \times Вn \times Кn_i,$$

где:

$Сб_i$ – базовая ставка арендной платы, установленная в i-м муниципальном образовании, или норматив, определяющий затраты (тыс. рублей в сутки) на содержание помещений для бюджетных учреждений (включая эксплуатационные расходы) за 1 кв. метр в i-м муниципальном образовании;

Пn – норматив, определяющий площадь помещения (кв. метров);

Вn – норматив, определяющий период использования помещения (суток);

$Кn_i$ – количество помещений в i-м муниципальном образовании (единиц).

5. Размер затрат на обеспечение охраняемыми помещениями для хранения переписных листов и иных документов Всероссийской переписи населения 2020 года в i-м муниципальном образовании определяется по формуле:

$$Vохр_i = Соп \times Поп \times Воп \times Ко_i,$$

где:

Соп – норматив, определяющий стоимость обеспечения охраняемыми помещениями для хранения переписных листов и иных документов Всероссийской переписи населения 2020 года при круглосуточном режиме работы за 1 кв. метр в i-м муниципальном образовании (тыс. рублей в сутки);

Поп – норматив, определяющий площадь охраняемых помещений для хранения переписных листов и иных документов Всероссийской переписи населения 2020 года (кв. метров);

Воп – норматив, определяющий период обеспечения охраняемыми помещениями для хранения переписных листов и иных документов Всероссийской переписи населения 2020 года (суток);

$Ко_i$ – количество охраняемых помещений для хранения переписных листов и иных документов Всероссийской переписи населения 2020 года в i-м муниципальном образовании (единиц).

6. Размер затрат на предоставление необходимых транспортных средств, средств связи в i-м муниципальном образовании определяется по формуле:

$$Vтрс_i = Стп \times Тп \times Т_i + Сп \times Сс \times Тс_i,$$

где:

Стп – норматив, определяющий стоимость транспортных услуг (тыс. рублей в час);

Тп – норматив, определяющий период предоставления транспортных услуг (часов);

$Т_i$ – количество транспортных средств в i-м муниципальном образовании

(единиц);

Сп – норматив, определяющий стоимость средств связи (тыс. рублей в сутки);

Сс – норматив, определяющий период предоставления средств связи (суток);

$Тс_i$ – количество предоставляемых средств связи в i-м муниципальном районе или городском округе (единиц).

7. Нормативы Вп, Воп, Тп, Сс, Пп, Поп, предусмотренные настоящей Методикой, определяются уполномоченным федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим функции по формированию официальной статистической информации о социальных, экономических, демографических, экологических и других общественных процессах в Российской Федерации (далее – уполномоченный федеральный орган).

8. Нормативы Сбi, Соп, Стп, Сп, предусмотренные настоящей Методикой, определяются специально уполномоченным органом в рамках предельной стоимости нормативов, установленных уполномоченным федеральным органом.

9. Количество помещений, охраняемых, оборудованных мебелью, средствами связи и пригодными для обучения и работы лиц, привлекаемых к сбору сведений о населении, количество охраняемых помещений для хранения переписных листов и иных документов Всероссийской переписи населения 2020 года, количество транспортных средств, количество предоставляемых средств связи определяются специально уполномоченным органом на основании нормативов, установленных уполномоченным федеральным органом.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 26 ноябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Бөтенроссия халык санын алу турында» 2002 елның 25 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына гамәлгә ашыру өчен тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен (алга таба – вәкаләтләр) бирә.

2 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган вәкаләтләр**

Җирле үзидарә органнарына түбәндәге вәкаләтләр бирелә:

1) саклана торган, җиһазлар, элемтә чаралары урнаштырылган һәм халык турында белешмәләр җыюга җәлеп ителә торган затларны укыту һәм аларның эше өчен яраклы булган бүлмәләр белән тәэмин итү;

2) 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләрен һәм башка документларын саклау өчен саклана торган бүлмәләр белән тәэмин итү;

3) кирәкле транспорт чаралары, элемтә чаралары бирү.

3 статья. **Җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемнәре**

Вәкаләтләр Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләре (алга таба – муниципаль берәмлекләр) җирле үзидарә органнарына бирелә:

Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.

4 статья. **Җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр бирелә торган срок**

Җирле үзидарә органнарына вәкаләтләр 2021 елга бирелә.

5 статья. **Вәкаләтләрне финанс белән тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла.

Җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрне гамәлгә ашыруына субвенцияләр Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә.

2. Җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрне гамәлгә ашыруы өчен субвенцияләрнең гомуми күләме һәм аны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү әлеге Законга кушымтада каралган Җирле үзидарә органнарының 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруы өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү методикасы нигезендә билгеләнә.

3. Җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрне гамәлгә ашыруы өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләме

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

6 статья. **Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар, вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен кирәк булган очракта, тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла.

2. Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген төзү, аны раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча җаваплы итеп билгеләнә торган вәкаләтле органының (алга таба – махсус вәкаләтле орган) җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә гамәлгә ашырыла.

7 статья. **Вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) вәкаләтләрне Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләр исәбеннән финанс белән тәэмин итәргә;

2) вәкаләтләрне кирәкле матди чаралар белән тәэмин итәргә;

3) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлек уставында каралган очракларда һәм тәртиптә өстәмә рәвештә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга;

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати, консультатив, оештыру ягыннан һәм методик ярдәм алырга.

2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы җирле үзидарә органнарын һәм аларның вазыйфаи затларын билгеләргә;

2) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын, шулай ук вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үз компетенцияләре чикләрендә кабул ителгән актларын үтәргә;

3) Татарстан Республикасы милкендә булган һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла торган матди чараларны исәпкә алуны һәм рациональ файдалануны, вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән финанс чараларыннан

нәтиҗәле һәм максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

4) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, әлеге максатларга бүлеп бирелгән матди чаралардан һәм финанс чараларыннан файдалану белән бәйле кирәкле мәгълүматны һәм документларны тапшырырга;

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру һәм финанс чараларын тоту турында хисаплар тапшырырга;

6) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына вәкаләтләрнең гамәлгә ашырылуын тикшереп торуда ярдәм күрсәтергә.

8 статья. **Җирле үзидарә органнары вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. «Бөтенроссия халык санын алу турында» 2002 елның 25 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Президенты:

җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләр гамәлгә ашырылуның нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын тикшереп торуны тәэмин итә;

әлеге Законның 1 статьясы нигезендә бирелгән вәкаләтләр үтәлмәгән яисә тиешенчә үтәлмәгән очракта, аларның җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылуын туктату турында закон чыгару инициативасын тәкъдим итә.

2. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) мәҗбүри үтәлергә тиешле норматив хокукый актлар кабул итәргә һәм аларның үтәлешен тикшереп торырга;

2) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру белән бәйле мәгълүмат, материаллар һәм документлар соратып алырга;

3) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру барышында җирле үзидарә органнары яисә аларның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларны бетерү буенча, шул исәптән әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү буенча, язма күрсәтмәләр бирергә;

4) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашырырга.

3. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле матди чараларны һәм финанс чараларын җирле үзидарә органнарына тапшырырга;

2) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен карарга;

3) җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләр үтәлүне, шулай ук бу максатларга бирелгән матди чараларны һәм финанс чараларын куллануны тикшереп торырга;

4) җирле үзидарә органнарына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча алар тарафыннан соратып алынган мәгълүматны бирергә;

5) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати, консультатив, оештыру ягыннан һәм методик ярдәм күрсәтергә.

9 статья. **Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм рәвешләрдә тапшырыла.

10 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрнең гамәлгә ашырылуын тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрнең гамәлгә ашырылуын тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) махсус вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге юллар белән:

а) вәкаләтләрне үтәү турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алу;

б) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 77 статьясында каралган тәртиптә тикшерүләр үткәрү;

2) Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар әлеге Законда каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга бирелгән очракта, вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына бирелгән дәүләт мөлкәтенең сакланышы һәм аннан тиешенчә файдалану өлешендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан түбәндәге юллар белән:

а) вәкаләтләрне үтәү турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алу;

б) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 77 статьясында каралган тәртиптә тикшерүләр үткәрү;

в) хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү буенча кирәкле чаралар күрү;

3) вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан Россия Федерациясе бюджет законнары һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актлар нигезендә.

11 статья. **Җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрне гамәлгә ашыруын туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрне гамәлгә ашыруы Татарстан Республикасы законы белән түбәндәге очракта туктатыла:

1) җирле үзидарә органнары вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә;

2) җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары әлеге Законны бозуларны бетерү турында күрсәтмәләрне үтәмәгәндә;

3) федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары үзгәрү сәбәпле җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда.

2. Җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрне гамәлгә ашыруын туктату, вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелеп, файдаланылмый калган финанс чараларын һәм матди чараларны кире кайтаруны таләп итә.

3. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, махсус вәкаләтле орган күрсәтелгән закон бозулар ачыкланган көннән соң 10 көн эчендә җирле үзидарә органнарына аларны бетерү турында күрсәтмә җибәрә.

4. Ачыкланган закон бозуларны бетерү турында күрсәтмә җирле үзидарә органына кергән көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча мәҗбүри каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре турында кичекмәстән язма рәвештә махсус вәкаләтле органга хәбәр ителә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда махсус вәкаләтле орган җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрне гамәлгә ашыруын туктату турында тәкъдимне һәм Татарстан Республикасының тиешле закон проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертә.

12 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 11 декабрь
№ 86-ТРЗ

«Татарстан Республикасы
муниципаль районнарының һәм
шәһәр округларының җирле үзидарә
органнарына 2020 елгы Бөтенроссия
халык санын алуны әзерләү һәм
үткәрү буенча Россия Федерациясе
вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Җирле үзидарә органнарының 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруы өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү методикасы**

1. Әлеге Методика җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрне гамәлгә ашыруы өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү максатларында эшләнде.

2. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме ($V_{РТ}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{РТ} = \sum_{i=1}^{n} V_{ОБЩi},$$

монда:

n – вәкаләтләр бирелгән муниципаль берәмлекләр саны;

i – муниципаль берәмлек;

$Vобщ_i$ – i-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме (мең сум).

3. I-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Vобщ_i = Vрпу_i + Vохр_i + Vтрс_i,$$

монда:

$Vрпу_i$ – i-муниципаль берәмлегендә саклана торган, җиһазлар, элемтә чаралары урнаштырылган һәм халык турында белешмәләр җыюга җәлеп ителә торган затларны укыту һәм аларның эше өчен яраклы булган бүлмәләр белән тәэмин итүгә чыгымнар күләме;

$V_{oxp_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләрен һәм башка документларын саклау өчен саклана торган бүлмәләр белән тәэмин итүгә чыгымнар күләме;

$V_{трс_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә кирәкле транспорт чараларын, элемтә чараларын бирүгә чыгымнар күләме.

4. I-муниципаль берәмлегендә саклана торган, җиһазлар, элемтә чаралары урнаштырылган һәм халык турында белешмәләр җыюга җәлеп ителә торган затларны укыту һәм аларның эше өчен яраклы булган бүлмәләр белән тәэмин итүгә чыгымнар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{рпу_i} = Cб_i \times Пn \times Bn \times Kn_i ,$$

монда:

$Cб_i$ – i-муниципаль берәмлегендә билгеләнгән аренда түләвенең база ставкасы яисә i-муниципаль берәмлегендә бюджет учреждениеләре өчен бүлмәләрне карап тотуга (эксплуатацияләү чыгымнарын да кертеп) 1 кв. метр өчен чыгымнарны (тәүлегенә мең сум) билгели торган норматив;

Пn – бүлмә мәйданын билгели торган норматив (кв. метр);

Bn – бүлмәдән файдалану чорын билгели торган норматив (тәүлек);

$Kn_i$ – i-муниципаль берәмлегендә бүлмәләр саны (берәмлек).

5. I-муниципаль берәмлегендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләрен һәм башка документларын саклау өчен саклана торган бүлмәләр белән тәэмин итүгә чыгымнар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{oxp_i} = Con \times Пon \times Bon \times Ko_i ,$$

монда:

Con – i-муниципаль берәмлегендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләрен һәм башка документларын саклау өчен саклана торган бүлмәләр белән тәүлек буе эшләү режимында тәэмин итүнең 1 кв. метр өчен бәясен билгели торган норматив (тәүлегенә мең сум);

Пon – 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләрен һәм башка документларын саклау өчен саклана торган бүлмәләр мәйданын билгели торган норматив (кв. метр);

Bon – 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләрен һәм башка документларын саклау өчен саклана торган бүлмәләр белән тәэмин итү чорын билгели торган норматив (тәүлек);

$Ko_i$ – i-муниципаль берәмлегендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләрен һәм башка документларын саклау өчен саклана торган бүлмәләр саны (берәмлек).

6. I-муниципаль берәмлегендә кирәкле транспорт чараларын, элемтә чараларын бирүгә чыгымнар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{трс_i} = Cтn \times Tn \times T_i + Cn \times Cc \times Tc_i ,$$

монда:

Стп – транспорт хезмәтләре күрсәтү бәясен билгели торган норматив (сәгатенә мең сум);

Тп – транспорт хезмәтләре күрсәтү вакытын билгели торган норматив (сәгать);

$T_i$ – i-муниципаль берәмлегендә транспорт чаралары саны (берәмлек);

Сп – элемтә чаралары бәясен билгели торган норматив (тәүлегенә мең сум);

Сс – элемтә чаралары биру чорын билгели торган норматив (тәүлек);

$Tc_i$ – i-муниципаль районында яисә шәһәр округында бирелә торган элемтә чаралары саны (берәмлек).

7. Әлеге Методикада каралган Вп, Воп, Тп, Сс, Пп, Поп нормативлары Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистика мәгълүматын булдыру функцияләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы (алга таба – вәкаләтле федераль орган) тарафыннан билгеләнә.

8. Әлеге Методикада каралган Сбi, Соп, Стп, Сп нормативлары вәкаләтле федераль орган билгеләгән нормативларның чик бәяләре кысаларында махсус вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

9. Саклана торган, җиһазлар, элемтә чаралары урнаштырылган һәм халык турында белешмәләр җыюга җәлеп ителә торган затларны укыту һәм аларның эше өчен яраклы булган бүлмәләр саны, 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуның сан алу кәгазьләрен һәм башка документларын саклау өчен саклана торган бүлмәләр саны, транспорт чаралары саны, бирелә торган элемтә чаралары саны, вәкаләтле федераль орган тарафыннан билгеләнгән нормативларга нигезләнеп, махсус вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.